Мортыштамак төп гомуми
белем бирү мәктәбе

***Парламент дәресе***

# ГРАЖДАНИН ҺӘМ САЙЛАУЛАР.

4 сыйныф укучылары өчен

**Автор: I нче категорияле
башлангыч сыйныф укытучысы
Газизова Гүзәлия Фирдәвис кызы**

**Максат:**

1. Укучыларда политик культура, гражданлык үзаң нигезләрен, сайлаулар аша дәүләт эшләре белән идарә итүдә катнашу мөмкинлеге турында беренчел күзаллауны формалаштыру. Демократик җәмгыятьтә сайлау һәм сайлаучы хокукларының принципларын ачыклау; сайлау процессында сайлаучыларның ролен аңлату; укучыларны сайлау законодательствосы белән таныштыру

2. Информацион, коммуникатив күнекмәләрне үстерү.

3. Актив гражданлык позициясе формалаштыру.

**Җиһазлау:**

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт символлары, гимннары, бирем белән карточкалар.

**Әдәбият:**
1. РФ, ТР Конституцияләре.
2. Җирле үзидарә турында Закон (12.07.2010 г.)
3. ФЗ №131 (МСУ) (12.07.2010 г.)
4. ТР Сайлау кодексы(12.07.2010 г.)

**Дәрес барышы.**

**1. Оештыру моменты.**

"Гражданин һәм сайлаулар" темасына багышланган парламент дәресен башлыйбыз.

Российской Федерациясе, Татарстан Республикасы гимннары яңгырый.

**Сайлаулар төшенчәсе.**

**Укытучы:** Без барыбыз да Россия гражданнары. Гражданин булу нәрсә ул?
*(Укучылар җавабы: Законнарга буйсыну, үз хокукларың һәм вазифаларың булу)*
**Укытучы гомумиләштерә:**Россия Федерациясе Конституциясе гражданнарның хокукларын, вазифаларын билгели. Илебез гражданнарының иң төп хокукларының берсе – сайлауларда катнашу.
**Укытучы**: Балалар, кайсыгыз әйтә ала, нәрсә ул сайлаулар?
**Укучылар:**Сайлауларда депутатларны, президентны сайлыйлар.

**Укытучы:** Дөрес, аларны сайлау нәтиҗәсендә безнең илдә дәүләт хакимияте органнары формалаша. Әйдәгез аларны искә төшерик, без алар турында нәрсә беләбез?Россиядә законнарны кемнәр кабул итә?
**Укучылар:**Депутатлар.
**Укытучы:**Ә депутатлар кайда эшлиләр?
**Укучылар:**Россия Федерациясенең Дәүләт Думасында.
**Укытучы:**Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы илнең ***закон чыгару, вәкиллекле*** органы булып тора. **Закон чыгару органы**, чөнки Дума законнар кабул итә. **Вәкиллекле**, чөнки депутатлар үзләрен сайлаган сайлаучыларның теләкләрен, уй-фикерләрен белдерәләр, безнең һәрберебез өчен бик кирәкле булган сорауларны хәл итәләр. Ә сайлаучылар алар – сезнең әти-әниләрегез, әби-бабайларыгыз, абый-апаларыгыз. Татарстан Республикасында закон чыгару органы ничек атала?
**Укучылар:** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы.
**Укытучы:** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы биш елга сайлана һәм 100 депутаттан тора. 21 яшькә җиткән граждан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты булып сайланырга мөмкин. Республика Дәүләт Советы рәисе - Фәрид Хәйрулла улы Мөхәммәтшин. Балалар, әйтегез әле, Дәүләт Думасы яки Дәүләт Советы кабул иткән законнарны кем үти?
**Укучылар:** Министрлар, Хөкүмәт.
**Учитель:** Дөрес. Законнарны үтәүче орган башкарма орган - хөкүмәт дип атала, һәм аңа барлык министрлар керә. Россия Федерациясе Хөкүмәте – дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы. Татарстан Республикасында андый орган – Министрлар Кабинеты.
**Учитель:** Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы илнең тормышында зур роль уйныйлар. Депутатлар ил һәм республика өчен бик мөһим мәсьәләләрне хәл итәләр. Ләкин кайбер сораулар конкрет шәһәрдә яки авылда яшәүче гражданнар катнашында чишелергә мөмкин. Аларны хәл итү өчен вәкиллекле җирле үзидарә органы бар. Ул шулай ук депутатлардан тора. Безнең районныкы – Сарман муниципаль район Советы, авылныкы – Мортыш-Тамак авыл җирлеге Советы дип атала. **Быел, 10 октябрьдә** вәкиллекле җирле үзидарә органнарына депутатлар сайлаулары үтәчәк.
**Укытучы:** Балалар, Россия Президенты нинди эшләр башкара?
**Укучылар:** Ул ил башлыгы булып тора, илнең һәм халыкның мәнфәгатьләрен яклый.
**Укытучы:** Балалар, үскәч кайсыгызның президент яки депутат буласы килә?
**Укучылар:** …!
**Учитель:** Депутатларны да, Россия Президентын да халык сайлый. Бу хокук 18 яше тулган һәрбер гражданинга бирелә. Сезгә 18 яшь тулгач, җирле үзидарә органы депутаты, 21 яшьтән – Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы яки Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты булып сайлана аласыз. Ә 35 яшь тулгач, Россия Президенты була аласыз.
**Укытучы:** Сайлауларда катнашу – РФнең һәрбер гражданиның хокукы.

**Сайлаучы үз иленең киләчәген сайлый.**
**Сайла! Оттырма!**

*(Балалар югарыдагы җөмләләрнең мәгънәсен аңлаталар)*

**Ныгыту.**

***"Дүртенчесе - артык" уены.***
***Артыкның астына сыз.***
*(Балалар артык сүзне әйтәләр һәм аңлаталар)*

1) Россия флагының төсләре:
*Зәңгәр, кызыл, яшел, ак.*

2) Татарстан флагының төсләре:
*Зәңгәр, яшел, кызыл, ак.*

3) Сайлауларда кемнәр катнаша:
*Әти-әниләр, әби-бабайлар, балалар.*

4) Россия Президентлары:
*Б. Н. Ельцин, В. В. Путин, М.Ш. Шәймиев, Д.А. Медведев.*

5) Россиянең, Татарстанның, районның закон чыгару органнары:
*Дәүләт Думасы, Дәүләт Советы, Хөкүмәт, Сарман муниципаль район Советы.*

**Йомгаклау.**

Укытучы: Миңа сезнең белән дәрес үткәрү кызыклы булды. Күрәм, сез - илнең чын гражданнары. Сез туган җиребезнең патриотлары булырсыз дип ышанам. Дәресебез тәмам.

**“Дүртенчесе - артык” уены.**
**Артыкның астына сыз.**
*(Балалар артык сүзне әйтәләр һәм аңлаталар)*

1) Россия флагының төсләре:
*Зәңгәр, кызыл, яшел, ак.*

2) Татарстан флагының төсләре:
*Зәңгәр, яшел, кызыл, ак.*

3) Сайлауларда кемнәр катнаша:
*Әти-әниләр, әби-бабайлар, балалар.*

4) Россия Президентлары:
*Б. Н. Ельцин, В. В. Путин, М.Ш. Шәймиев, Д.А. Медведев.*

5) Россиянең, Татарстанның, районның закон чыгару органнары:
*Дәүләт Думасы, Дәүләт Советы, Хөкүмәт, Сарман муниципаль район Советы.*